**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегенең Янтуган авылында гражданнар җыены карары**

23.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Янтуган авыл җирлегенең Янтуган авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2023 елда Янтуган авыл җирлегенең Янтуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 700 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Янтуган авылында кышкы чорда юлларны карап тотуга, җәйге вакытта территорияне чабуга (ягулык-майлау материаллары, запас частьлар алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләүгә), юлларны ремонтлауга юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Янтуган авыл җирлегенең Янтуган авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Янтуган авыл җирлеге башлыгы _________ Р.А. Җамалтдинов

Халык җыены секретаре _________ Г.З. Гәйнетдинова